# «Кошлар – безнең дусларыбыз»





***Песнәк тәрәз каршында,***
***Түшесарылимон күк.***
***Кара бүрек башында,***
***Юри киеп куйган күк***



*Тукран һәр агач саен*
*Тук-тук сугып карый,*
*Кошчыкның очлы борыны*
*Кирәкле эшкә ярый.*
*Агач корытучы кортларны,*
*Эзләп, чокып бетерә,*
*“Урман докторы” булып ул*
*Илгә файда китерә.*




Язын ерак-ераклардан
Очып килде каргалар,
Тал башына зур бер шәһәр
Тезеп куйдылар алар.
Без каршы алдык аларны
Үз итеп, сөеп,
Диңгез, чүлләрне исән-сау
Кичкәнсез, - диеп.



**Җылы яклардан**
**Сыерчык килде.**
**Мин куйган яңа**
**Ояга керде.**
**Шундый сөенде,**
**Ошаткач инде...**
**Оя кырында**
**Чыбыкка басып**
**Үзе турында**
**Сөйләде ачык.**



***Иртә язда басу һәм далалар өстендә – биектә бер кош оча. Ул – тургай. Тургай канат кага-кага өздереп сайравы белән һәркемне таң калдыра, шулай итеп, ул игенчене кырга чакыра.***



***Нинди якты уйлар уйлап,***
***Кыр казлары, кыйгак-кыйгак,***
***Болын буйлап, кырлар буйлап***
***Кайта безгә язны зурлап.***
***Тезелешеп гаскәр кебек,***
***Ераклардан илләр гизеп,***
***Кычкыралар: “Кайттык урап,***
***Исәнмесез, кыйгак-кыйгак***”.

1. Агач башында йорты,
   Эчендә яши җырчы.
2. Кайсы кошның балалары әниләрен белми?
3. Нинди кош ялтыравык әйбергә кызыга?
4. Кайсы кош җылы яктан иң беренче булып каита?
5. Гөрли-гөрли җырлый ул,
   Кызыл читек кия ул.
   Күлмәкләре күгелҗем,
   Татулыкны сөя ул.
6. Иң матур койрыклы кош.
7. Дөньяда сан ягыннан иң күп таралган кошлар.
8. Бер кошым бар: тынмый,
   Агачка оя кормый.
   Өе – җирдә,
   Җыры – күктә.
9. Кулы юк – балчык ташый;
   Балтасы юк – оя ясый.
10. Нинди кошлар кар астында төн куна?
11. Нинди кошлар йомырка салмый?
12. Иң күп ашаучы кошның исемен әйтегез?

***1. Кайсысы кош түгел?***

А) ярканат

Б) пингвин

В) тавык

***2. Кошлар хайваннардан ничек аерыла?***

А) оча ала

Б) оя ясый

В) каурыйлары бар

***3. Кайсы кош көзен җылы якка китә?***

А) чыпчык

Б) карлыгач

В) песнәк

***4. Кайсы кош оча алмый?***

А) үрдәк

Б) страус

В) ябалак